Җиһаншина, Ф. Китапханәбез юбилее / Ф. Җиһаншина // Мәдәни җомга. – 2025. – №27 (11 июль). – Б. 4.

# Китапханәбез юбилее



Китапханә эшләгән дәвердә биредә үз эшләренә риясыз бирелгән кешеләр хезмәт куйган. Бу кешеләрнең барысы да хезмәттәшләренә генә түгел, ә һәр укучыга да игелек һәм белем биргәннәренә шатланганнар

Китапханә... Бүгенге көндә әлеге сүзнең гасырлар дәвамында формалашкан йөзләгән билгеләмәсе бар. Ләкин китапханәләрнең кеше тормышындагы ролен, асылын бер генә атама эченә сыйдырып буламы икән ул? Минемчә, юктыр. Чөнки анда гына барлык төр мәгълүмат, үткән тарихыбыз, олысына да, кечесенә дә ярдәмгә килерлек киңәшләр урын алган. Әгәр китаплар сакланмаган булса, галимнәребез, язучыларыбыз үзләренең ачышларын китап битләренә язып шәкертләренә өйрәтеп калдырмаган булса, тарихыбыз турында кеше сөйләгәннәрдән генә күп мәгълүмат алып булмас иде. Үткәне булмаган халыкның киләчәге дә юк, дип юкка гына әйтмәгән шул борынгылар. Китапханә ул - бер буыннан икенче буынга калдырылган рухи мирас. Бар да үзгәрә: кешелек, дәүләтләр. Ә китап - мәңгелек'

Сезне Чаллы шәһәренең ин өлкән китапханәләренең берсе - 1 нче номерлы китапханә белән таныштырасым килә. Теләсә кайсы китапханәнең тарихы ил, шәһәр тарихы һәм анда эшләүчеләрнең язмышына тыгыз үрелеп баруы белән игътибарга лаек. 1 нче номерлы китапханә дә искәрмә түгел, ул да гаять зур юл үтте, быел анын ачылуына 65 ел тулды.

1 нче номерлы шәһәр китапханәсе 1960 елның 1 июлендә ЗЯБ бистәсендә урнашкан «Строитель» клубында ачыла. Бу шәһәр халкы өчен зур вакыйгага әверелә. Китапханә ике бүлмәле була. китап фонды 501 данә тәшкил итә. Ул вакытта китапханә белән 646 кеше файдаланган. 1964 елның мартында китапханә Һ.Такташ урамындагы 45 йорт адресы буенча яңа бинага күчә. Китапханәнең мәйданы 167 кв.м., ә фонды 15000 данәгә кадәр арта. Ул вакытта китапханәдән укучылар күп була. Китапханә тирәсендә эшчеләр тулай торагы урнашкан, һәм аларның күбесе китапханә укучылары булган. Ул чакта ук мәктәпләрдә һәм тулай торакларда төрле чаралар үткәрелгән.

«Мин берникадәр вакыт китап ташучы булдым, - дип искә ала элеккеге китапханәче Һадиева Лидия Әхтәс кызы. - Китап тутырылган чемодан белән кирпеч заводына, сөт заводына йөрдем. Анда үз укучыларым - гади эшчеләр бар иде. Эшләү кызык иде. Яшьләр күп. Комсомол җыеннары, КамАЗ төзүчеләре, язучылар, артистлар, спортчылар белән очрашулар җанлы һәм кызыклы узды».

Бүген китапханә - үз микрорайонында мәгълүмат, мәгариф һәм мәдәният үзәге. Филиал коллективы укучыларга сыйфатлы хезмәт күрсәтү өчен бөтен көчен куя, бик теләп сөендерәләр. Күп кенә социаль якланмаган кешеләр өчен китап олы дөньяга бердәнбер тәрәзә, дус, киңәшче, табиб булып тора. ә китапханә, аларның тернәкләндерү һәм аралашу үзәгенә әверелә. Ш\"на күрә өлкәннәр һәм инвалидлар өчен «Вдохновение» клубы оештырылды. Клубта хөкем сөргән җылы гаилә мохите аларга җәмгыятьтәге картлык турындагы стереотиплар белән көрәшергә ярдәм итә. Китапханәгә килеп кергәч тә, анда тудырылган җылы мохит, чисталык, уку залы үзенә җәлеп итә. Китапханәдә китап сөючеләр өчен барлык шартлар да тудырылган - компьютер белән тәэмин ителгән, интернет челтәренә тоташтырылган. Актуаль темаларга туры китереп китап күргәзмәләре эшләп тора. Мәктәп укучысымы син, студентмы, өлкән буын вәкилеме, һәр төркем өчен аерым бүлек булдырылган. Үзеңә кирәкле әдәбиятны табып укы гына!

**Фирдая ҖИҺАНШИНА,**

1 нче номерлы китапханә хезмәткәре